**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№9458**
**04.10.2023**

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, контракт буенча хәрби хезмәт узучы яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән арендаторлар белән төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләрен, җир участокларын арендалау шартнамәләрен өзү һәм аренда түләвен түләүне кичектереп тору турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясының 7 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларга дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» 2022 елның 16 ноябрендәге 2507-р номерлы боерыгы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, контракт буенча хәрби хезмәт узучы яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән арендаторлар белән төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләрен, җир участокларын арендалау шартнамәләрен өзү һәм аренда түләвен түләүне кичектереп тору турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага,

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 4 октябрендәге
9458 номерлы карарына
кушымта

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, контракт буенча хәрби хезмәт узучы яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән арендаторлар белән төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләрен, җир участокларын арендалау шартнамәләрен өзү һәм аренда түләвен түләүне кичектереп тору турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яки «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясының 7 пункты нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт узучы яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән, бер үк физик зат юридик затны бедәнбер гамәлгә куючы (катнашучы) һәм аның җитәкчесе булып торган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар булып саналган арендаторлар (алга таба – арендатор) белән төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләрен, җир участокларын арендалау шартнамәләрен (алга таба – аренда шартнамәсе) өзү һәм аренда түләвен түләүне кичектереп тору тәртибен билгели.

2. Кичектереп тору муниципаль милектәге мөлкәткә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына (алга таба – мөлкәт) карата бирелә.

3. Кичектереп тору чорында мөлкәтне карап тотуга бәйле аренда шартнамәсе буенча коммуналь түләүләр арендага бирүче тарафыннан түләнә.

4. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән аренда түләвен кичектереп тору срогына, кичектереп тору сәбәпле штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яки арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле башка җаваплылык чаралары (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кулланылмый.

5. Кичектереп тору арендаторның (арендатор вәкиленең) гаризасы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча (алга таба – мобилизация буенча) хәрби хезмәт узу яки «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясының 7 пункты нигезендә төзелгән контракт буенча (алга таба – контракт буенча) яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ирекле ярдәм күрсәтү турында төзелгән контракт буенча (алга таба – ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт буенча) 90 көнгә кадәр озайтылган хәрби хезмәт узу срогына бирелә һәм түбәндәге шартлар үтәлгәндә озайтыла:

1) кичектереп тору чорында аренда шартнамәсе буенча бирелгән мөлкәт арендатор тарафыннан файдаланылмый;

2) кичектереп тору бирелә торган аренда түләүләренең суммасы, аренда шартнамәсенә өстәмә килешү нигезендә, аренда түләвен түләүне кичектереп тору чоры тәмамланган көннән башлап этаплап, айлык аренда түләвенең күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләр күләмендә, айга бер тапкыр түләнергә тиеш.

6. Кичектереп тору арендаторның мобилизация буенча, контракт буенча яисә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт буенча хәрби хезмәт узу чорында бурычларны үтәгәндә алынган имгәнүләрдән (яралану, травма, контузия) яки авырулардан дәвалануда стационар шартларда хастаханәдә, госпитальдә, башка медицина оешмаларында булу чорына озайтыла.

Арендатор хәбәрсез югалган дип танылган очракта, кичектереп тору срогы аны хәбәрсез югалган дип тану турында суд карары гамәлдән чыгарылганчы яисә суд аны үлгән дип игълан иткәнче озайтыла.

7. Кичектереп тору чорына аренда түләүләре арендага бирүче тарафыннан түбәндәге очракларда түләтелми:

1) мобилизация буенча, контракт буенча яисә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт буенча хәрби хезмәт узу чорында арендаторның һәлак булуы (үлеме), яисә күрсәтелгән чордан соңрак, ләкин мобилизация буенча, контракт буенча яисә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт буенча хәрби хезмәт узу чорында алынган имгәнүләр (яралану, травма, контузия) яки авыру нәтиҗәсендә;

2) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, мобилизация буенча, контракт буенча яисә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт буенча хәрби хезмәт узу чорында алынган имгәнүләр (яралану, травма, контузия) яки авырулар нәтиҗәсендә арендаторны I группа инвалид дип тану.

8. Мобилизация буенча, контракт буенча яисә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт буенча хәрби хезмәт узу чорында алынган һәм үлемгә яки Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә 1 группа инвалид дип тануга китергән имгәнүләр (яралану, травма, контузия) яки авырулар турында мәгълүмат хәрби-табиб комиссиясе һәм (яки) федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан раслана.

9. Кичектереп тору өчен нигез булып арендаторның (арендатор вәкиленең) Башкарма комитетка юлланган гаризасы тора.

10. Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

1) арендаторның (арендатор вәкиленең) шәхесен раслый торган документ күчермәсе;

2) арендатор вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, арендатор вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсе (алга таба – документлар).

11. Арендатор шәхсән үзе яки арендатор вәкиле почта элемтәсе аша яки kancel.chelny@tatar.ru электрон почта адресына Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә, әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп,. гариза бирә.

12. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе гаризаны терки һәм карап тикшерү өчен, шул ук көнне Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

13. Башкарма комитет Җитәкчесе бер эш көне эчендә гаризаны, документларны карап тикшерә һәм Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә (алга таба – ҖММИ) җибәрә.

14. Гариза кергән датадан башлап бер эш көне эчендә ҖММИ белгече гаризаны, документларны карап тикшерә һәм арендаторның мобилизация буенча, контракт буенча яисә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт буенча хәрби хезмәт узуы турында Башкарма комитетның мобилизация бүлегенә запрос җибәрә.

15. Башкарма комитетның мобилизация бүлеге белгече ике эш көне эчендә ҖММИгә арендаторның мобилизация буенча, контракт буенча яисә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт буенча хәрби хезмәт узуы турында мәгълүмат яисә хәрби хезмәткәрләр исемлекләрендә арендатор турында мәгълүмат булмау турында мәгълүмат җибәрә.

16. Торак булмаган бинага карата кичектереп тору бирелгән очракта, ҖММИ белгече гариза кергән датадан башлап биш эш көне эчендә, аның файдаланылмавын тикшерү өчен әлеге бинага бара, бинаны печатьләп куя, торак булмаган бинадан файдаланмау яки файдалану турында акт төзи.

17. ҖММИгә гариза кергән датадан башлап биш эш көне эчендә җир участогына карата кичектереп тору бирелгән очракта, ҖММИ белгече Башкарма комитетының административ-техник инспекция идарәсе белгече белән берлектә җир участогыннан файдалануны тикшерүне гамәлгә ашыралар һәм җир участогын тикшерү акты төзиләр.

18. Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктының 1 пунктчасы нигезендә кичектереп торуны бирү шартлары бозылганда, ҖММИгә гариза кергән көннән башлап җиде эш көне эчендә, ҖММИ белгече арендаторга (арендатор вәкиленә) кичектереп торуны бирүдән баш тарту турында хат җибәрә.

19. Кичектереп тору өчен шартлар үтәлгәндә, ҖММИгә гариза кергән көннән башлап җиде эш көне эчендә ҖММИ белгече арендаторга (арендатор вәкиленә) мобилизация буенча, контракт буенча яисә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт буенча хәрби хезмәт узуга бәйле рәвештә аренда түләвен түләүне кичектереп тору турында белдерү кәгазе (әлеге Нигезләмәгә кушымта) җибәрә һәм кичектереп тору турындагы мәгълүматларны Башкарма комитетның финанс идарәсенә җибәрә.

20. Кичектереп тору чоры тәмамланган көннән башлап җиде эш көне эчендә ҖММИ белгече аренда шартнамәсенә өстәмә килешү проектын әзерли һәм имзалау өчен аны арендаторга (арендатор вәкиленә) җибәрә.

21. Муниципаль казна составындагы җир участокларын һәм торак булмаган биналарны арендалау шартнамәләре буенча арендатор (арендатор вәкиле) аренда шартнамәсенә өстәмә килешү проекты кергән вакыттан башлап дүрт эш көне эчендә әлеге проектны имзалый һәм имзалау өчен ҖММИгә кире кайтара.

22. Муниципаль учреждениеләргә һәм муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында яки муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән торак булмаган биналарны арендалау шартнамәләре буенча:

1) арендатор (арендатор вәкиле) аренда шартнамәсенә өстәмә килешү проекты кергән вакыттан башлап ике эш көне эчендә әлеге проектны имзалый һәм имзалау өчен арендага бирүчегә тапшыра;

2) арендага бирүче аренда шартнамәсенә өстәмә килешү проекты кергән вакыттан башлап ике эш көне эчендә әлеге проектны имзалый һәм имзалау өчен ҖММИгә җибәрә.

23. Аренда шартнамәсенә өстәмә килешү проекты ҖММИгә кергән вакыттан башлап биш эш көне эчендә, ҖММИ башлыгы өстәмә килешү проектын имзалый һәм ҖММИ белгече аны аренда шартнамәсенә өстәмә килешүләрне теркәү журналында терки.

24. Әгәр аренда шартнамәсе хокукларны теркәү органында теркәлгән булса, арендага бирүче, законда билгеләнгән тәртиптә, хокукларны теркәү органында аренда шартнамәсенә өстәмә килешүне дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итә.

25. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктының 1 пунктчасы нигезендә кичектереп тору суммасын гамәлдән чыгару өчен нигезләр булганда, Башкарма комитетның

2019 елның 25 сентябрендәге 4863 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе нигезендә, кичектереп тору суммалары гамәлдән чыгарылырга тиеш.

26. Аренда шартнамәсен өзгәндә штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яки аренда шартнамәсен өзүгә бәйле башка җаваплылык чаралары кулланылмый (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракта).

27. Аренда шартнамәсе арендага бирүче тарафыннан аренда шартнамәсен өзү турында белдерү кәгазе алынган көннән башлап өзелергә тиеш.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, контракт буенча хәрби хезмәт узучы яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән арендаторлар белән төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләрен, җир участокларын арендалау шартнамәләрен өзү һәм аренда түләвен түләүне кичектереп тору турында нигезләмәгә кушымта

Арендаторга (арендатор вәкиленә) ____________

Аренда шартнамәсе буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору турында белдерү кәгазе _______________ № _______

_________________________________________________________ (Арендага бирүче) һәм __________________________________(Арендатор) арасында _____________ № _____ аренда шартнамәсе (алга таба – аренда шартнамәсе) төзелде.

Сезнең «____» ______________ гариза (арендатор яки арендатор вәкиленең гаризасының керү №) нигезендә Башкарма комитет __________ № _____ аренда шартнамәсе буенча «____» ______________ башлап аренда түләвен түләүне кичектереп торуны бирү турында хәбәр итә.

Башкарма комитетның
җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр
идарәсе башлыгы ______________________